**Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены карары**

**18.11.2023** **№1**

«РоссияФедерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринципларытурында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедеральзаконның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасындаҗирлеүзидарәтурында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар , ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024елда үзарасалымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
-Үзәк урамындагы юлга асфальт салу.

1.2. гражданнарның2023 елда җыелган үзарасалымыннан калган 320468 сум күләмендәге акчаны түбәндәге чараны гамәлгә ашырырга:
- урам тренажерларын сатып алу.

2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.